**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2021 елның «17» июненнән　　　　　　　　　　　　　　　№ 259

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Опекунга опекага алынучыны яшәү урыны буенча теркәлү учетыннан төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 11 июлендәге 165 номерлы карары белән расланган опекунга опекага алынучыны яшәү урыны буенча теркәлү учетыннан төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 29 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 4330-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Опекунга опекага алынучыны яшәү урыны буенча теркәлү учетыннан төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 11 июлендәге 165 номерлы карары белән расланган опекунга опекага алынучыны яшәү урыны буенча теркәлү учетыннан төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5 пунктның г пунктчасындагы «опекага алынган затның яшәү урыны буенча фатир картасыннан өземтә (йорт кенәгәсеннән өземтә); опекага алынган кешенең киләсе яшәү урыны буенча фатир карточкасыннан, гаиләнең барлык

әгъзаларын күрсәтеп, өземтә (йорт кенәгәсеннән өземтә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең кетү һәм кабул итү урынына, шул исәптән федераль закончалык һәм Татарстан Республикасы закончалыгы нигезендә инвалидларны социаль яклау турындагы законы нигезендә әлеге объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм бизәүгә карата таләпләр» «Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән тәэмин ителгән биналарда алып барыла. Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү). Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатларында инвалидларны социаль яклау тәэмин ителә:

1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2 транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;

3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

6) махсус укытуын раслый торган документ һәм аны бирү тәртибен раслау турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Проводник-этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» гы 22.06.2015 № 386н боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта, проводник-этне кертергә рөхсәт итү.

Инвалидлар өчен муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга һәм әлеге пунктның 1 – 4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чараларга үтемлелекне тәэмин итү өлешендә 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата таләпләр кулланыла.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов